***Ирек САДЫЙКОВ,***

*Шәһри Казан газетасы җурналисты*

**ЯЗУЧЫ ЯЗМЫШЛАРЫ**

Шушы көннәрдә «Шәһри Казан» газетасы хәбәрчесе Чаллыда булып кайтты. Юбилей көннәренә туры килгән икән. Шәһәр язучылар оешмасына 15 яшь тулды. Шул уңайдан ул оешма сәркатибе Р.Хисмәтуллин белән очрашты.

– *Рәхмәтулла ага! Чаллы язучылар оешмасы төзелүгә шактый вакыт узган. Узган юлга борылып карасак, ул юктан гына барлыкка килмәгәндер ?*

– Юк, билгеле.Вакыт үткән саен Чаллы шәһәрендә беренче әдәби түгәрәкләр оештырып йөрүчеләрнең исемнәре дә артка чигенә бара, аларны бернинди чаралар белән дә мәңгеләштереп, гел истә тотып булмастыр. Әмма бүген үзэбезнең Чаллы оешмасының 15 еллыгын билгеләп үткән көннәрдә, утызынчы елларда «Трактор» газетасының мөхәррире булган шагыйрь Нур Баянны, инде бире таба килеп, әдәби дөньяны җанландыруга шактый өлеш керткән Габдрахман ага Маннаповны, әле яшьрәкләрдән Рафис Хисамиев, Разил Вәлиев, Фәннур Сафин, Шәүкәт Сибгатуллин, Анатолий Цыганов, Рәшит Юнысов, Миркадәм Матшин, Сәлимә Шәрипова, Андрей Колчерин, Мөдәррис Әгъләмовларны бик якты, олуг шәхесләр дип атасак, һич тә хата булмастыр.

Әмма чын әдәби уяну, чын мәдәни яшәеш, иҗади ачышлар Чаллыда рәсми Язучылар оешмасы ачылган көннән, ягьми 1980 елның гыйнварыннан башлангандыр дип беләм мин. Аны ачу эшләрендә Казаннан килгән мөхтәрәм язучыларыбыз Әмирхан Еники белән Илдар Юзеевлар урындагы әдәби җәмәгатьчелекне, әдәби көчләрне өйрәнеп, барлап йөргәннәр. Шул разведкадан соң оешма төзелеп, Эдуард Касыймов аның беренче җаваплы сәркатибе итеп сайлап куел.

Шушы көннән соң язучыларның хыялый, очынулы яңа яшәеше башлана. Анда татар шагыйрьләре Мәхмүт Газизов, Хәниф Хөснуллиннар КамАЗ һәм шәһәр төзелә торган җирләрдә субайчы-төзүчеләр, геодезистлар булып эшләп, буш вакытларында ашкына-ашкына иҗат итәләр. Аларның шигырьләре Татарстанда гына түгел, «Новый мир» һәм башка рус газета-журналлары аша Бөтенсоюз аренасында күтәрелә.

Эдуард Касыймов «Гигант» совхозында слесарь-сантехник, Равил Вәлиев башта түбә ябу конвейерында, аннары Мәүликов бригадасында төзүче булып эшләп, КамАЗ турында зур күләмле әсәрләр иҗат иттеләр.

Соңга таба аларның ашкын иҗат дулкынына ялкынлы публицист һәм фәлсәфи-шагыйрь Фаяз Дунай, күренекле шагыйрьләрдән Кадыйр Сибгатуллин, Нәҗип Мадьяровлар, керәшен дөньясының матур энҗеләре белән бизәлгән шигырьләр иҗат итүче Ямаш Игәнәй һәм балалар шагыйрәсе Рина Асылбаева кушылдылар.

*– Рәхмәтулла ага! Инде хәзерге буын язучыларына килгәндә, Чаллы төбәге зур хәзинә, шулай бит?!*

– Чыннан да, бу күзлектән чыгып караганда, без бик бай. Тора-бара шушы якларның төп хуҗасы, безнең барыбыз тарафыннан да бу төбәкнең президенты итеп танылырлык Рафис Сәлим бу куәтле төркемне фәлсәфи

Эзләнүләр белән баетып баетып, рухи яңарыш ягыннан көчле итеп күтәреп җибәрде. Шунысы кызык, шушы карт башым белән мин Рафисның фәлсәфәсен, дөньяны бик үзенчә танып белүен, аның оригиналь яшәү рәвешен дүрт-биш ел аралашканның соңында гына ныклап аңлый аддым. Беренчедән, башта «Елан мөгезе» дигән китабында мине аның теле сокландырган иде. Икенчедән, татар шәһәре турында язган трактаты бөтенләй сискәндереп җибәргән иде. Өченчедән, беренче кисәге өч-дүрт ел буена басылмый ятуга карамастан, «Амбар кенәгәсе»нең икенче кисәген язып ятуы аның бик төпле кеше икәнлегенә тәмам инандырды.

Рафис оештыру эшләрендә дә күпләргә үрнәк төстә «Мәгърифәт» нәшриятын аякка бастырды, бөтенләй юк җирдән милләткә хезмәт итә торган көчле база тудырды. Ул чын мәгънәсендә эш кешесе, талантлы оештыручы да икән.

Чаллы әдәби агымына Рәшит Бәшәрнең һәм Альберт Сафинның ярсулы, серле прозасы килеп кушылу безнең бу төбәк әдәбият хәрәкәтен һәм иҗатын зур биеклекләргә күтәреп җибәргәндәй булды. Әдәби тәнкыйтебез булмау аркасында гына әлегә без моны ныклап беркетеп куя алмадык.

Ә инде Кадыйр Сибгатуллин Балык Бистәсеннән үк үз итеп, олы әдәби юлга тартып чыгарган Вахит Имамов безнең барыбызга караганда да бәхетле иҗади язмышка юлыкты.

Ул Язучылар оешмасы ярдәме белән КамАЗ нәшриятының хуҗасы булып киткәч, бик күп иптәшләрнең китапларын бастырып чыгарды, ә иң мөһиме - китап бастыру эшенә Кашаповлар кебек киң күңелле, юмарт татар байларын җәлеп итә алды. Дөрес, алар арасында тукмагы минем башка да, .Вахитның үз башына да төшә торганнары да булды. Әмма без ул тукмаклардан гына егылмадык, аягыбызда торып калдык. Шушы |ныклык

нәтиҗәсендә «Сәет Батыр» дигән зур китабы дөньяга туды. Бу китапның 90 меңлек тираж белән чыгуы соңгы вакытта татар китап тарихында олы вакыйга булды.

Алардан соң килгән дулкын – үзенчәлекле шагыйрьләр Заһирә Гомәрова, Петр Прихожан, прозаиклар Вл.Кирилов, Михаил Гоголев, яшьләрдән Шамил Шәйдуллин, Нияз Вәлиев, Факил Әмәк, Әхмәт Дусайлы, Мирһади Разов һәм башкаларның иҗат җимешләрен республика күләмендә күреп алдылар. Ә Факил Әмәк, Әхмәт Дусай «Аргамак» журналында эшли башлагач, бу журналда язучыларның әсәрләрен калку итеп бастыру өчен күп көч куйдылар.

Мирһади Разовның җырлары көн саен диярлек клубларда, радио-телевидениедә яңгырау бәхетенә иреште.

*– Димәк, Рәхмәтулла ага, бернинди күчеш чорына карамастан, Чаллыда мәдәни-әдәби учак сүнми инде алайса?*

– Әйе, шәһәрдә әдәби хәрәкәт тукталып тормый, хәзер ул үзеннән-үзе бастырып чыгару мөмкинлеге булган матбугат органнары тирәсенә күчә бара. «Таң йолдызы», «Нур» газеталары каршында әдәби берләшмәләр хасил булды. Бу берләшмәләр без үтә торган караңгы тоннель сыман вакыт аралыгында утны-утка ялгап, кабызып баралар.

Табигый ки, бу күчеш чоры, сазлык аша дип әйтик, үтү чоры – язучының иҗатын гына түгел, аның матди яшәешенең дә астын-өскә китереп ташлады. Инде элеккечә сиңа күпмедер төшем китерерлек итеп китап чыгарып булмау турында әйткән дә юк. Аның урынына язучы хәзер йөрәге кушканны яза башлады. Бу безнең чорның гаҗәеп үзенчәлеге, бу - иҗат кешесе өчен күк капусы ачылып китү сыман олы бәхет. Ләкин сүз иреге, иҗат иреге ачылып китте дип кенә безнең элек-электән тукмалып, бирчәеп беткән рухи калебләребез алай бик нык, бик тиз ачылып китә алмады

Шул ук вакытта безнең язучы, китап басарга мөмкинлек юк дип, елап та утырмады. Йә үз хисабына, йә шунда спонсорын табып, үз әсәрләрен чыгара тордылар. Шулай итеп, Марсель Гыймазетдинов, Илгиз Аб-дуллин, Мирһади Разов, Фа-кил Әмәк, Әхмәт Дусайлы, Ирек Садыйков, Мансур Сафин, Фазыл Шәех, Шамил Шәйдуллин, Вахит Имамов, Венера Хәбибрахманова, Альберт Сафин һәм башкаларның китаплары дөнья күрее. Ә инде Рәшит Бәшәр тулы бер томлыгын чыгарып ята. Ягъни без элекке елларга караганда да күбрәк китап чыгара алдык дигән сүз.

*– Рәхмәтулла ага! Язучылар һәм милли хәрәкәт. Болар бер-берсе белән һич аерылгысыз бәйләнгән, минемчә.*

– Бу урында без, язучылар, милли хәрәкәт идеологларына шактый ук үпкәбезне белдерергә тиешбез. Андагы кайберәүләр язучыларны милли

хәрәкәттә катнашмауда гаеплиләр. Без моны тулысынча кире кагабыз. Ниөченме? Чөнки бүген күкрәк кагып батырланып йөрүчеләребез милли тел, мәдәният, татарлык турында әле уйлап та бирмичә, дөнья бишегендә бер кайгысыз гомер кичергәндә язучы халкы инде бик күп аддан туган тел, милләт дип сыкрана иде. Карагыз сез Эдуард Касыймовларның, искә төшерегез сез партия пленумында Чаллы татар мәктәпләрен, татар телен саклап калу турында ярсый-ярсый чыгыш ясаганнан соң Газиз Кашаловның инфаркт алып аяктан егылуын! Кайбер мәрхүмнәрнең үлемнәрен дә күпмедер дәрәҗәдә шушы милли кыерсыту-җәберләүләрнең корбаннары дип санагыз сез!

Ул тоталитар заманнарда партия кушуыннан башка җил дә исмәгән, яфрак та өзелеп төшмәгән чакларда шушы язучылар ич милләтнең зәгыйфь сулышын саклап калып, шушы көннәргә китереп җиткерүдә булыштылар.

Ә чынында бит Чаллыдагы милли хәрәкәт ул иң беренче язучылардан, аларның шигырьләреннән, роман-повестьларыннан, күз яшьле, әрнүле, рәнҗешле хикәяләреннән башланды.

«Аргамак» дигән журналга акчалата, тораклата һәм лицензияләтә иң әүвәл язучылар оешмасы нигез салды. Кызганыч, журнал безнең ярдәм белән чыга башлагач, үзенең тууына язучылар оешмасына бурычлы булуын язып чыга алмады. Ул гына да түгел, журнал турындагы уставны бозып, аны гамәлгә куючылар исемлегеннән бөтенләй сызып ташладылар. Дөньяда шундый хәлләр булгалый икән шул, нишләтәсең бит...

Нигә моны милләтчеләр күрми икән?

Бүгенге көндә, менә күрегез, милли китаплар чыгарабыз дип күкрәк киереп мактанып йөргән КамАЗ нәшриятын оештыруда да, әйткәнемчә, язучылар оешмасы башлап йөрде һәм башкарып чыкты! Ни өчендер, бу эштә дә язучылар оешмасы өлешен күрмиләр. Бу бит гаделсезлек.

Ул гына да түгел. Бездә әле тагын да кыюрак идеяләр туа тора. Ниһаять, КамАЗ нәшриятын тулысы белән язучылар милке итәр заман җитеп килә. Чөнки КамАЗның әле татар халкының рухи яңарышы, бөек бер халыкның ренессансы өчен зурдан кубып изгелекләр эшләгәне юк. Без моны да исбат итәчәкбез һәм бу нәшриятның Язучылар оешмасы карамагына күчүенә ирешергә тырышачакбыз. Бу идея үзе инде җиңүнең яртысыдыр дип беләм мин.

Онытмагыз, Чаллы татар матбугатында басылган иң төпле, иң тирән эчтәлекле, иң алдан күрүчәнлек белән, милли идея, милли рух белән сугарылган күпчелек мәкаләләрнең, радиодан чыгышларның авторлары да безнең язучылар иде.

«Иманга кайту» дигән телевизион фильмны да безнең оешма җимеше дип әйтә алабыз. Чөнки «Ак бүре» киностудиясенең рәсми юл башлап киткән

урыны язучылар оешмасы булды. Әмма, ничектер, моны да бик тиз оныттылар.

*– Рәхмәтулла ага, «Аргамак» журналын бер телгә алгач, һичничек сорамый булдыра алмыйм. Аның журналисты Ямаш Игәнәй «Шәһри Чаллы» газетасы аша Сезне, төрле гөнаһларда гаепләп, йөзегезне каралтырга маташкан иде. Сезнең җавап бик соң дөнья күрде. Моны ничек аңлатасыз?*

– Дустым, эш бер Ямаш Игәнәй белән миндә генә түгел. Тирәнрәк фикер йөрт. Әйе, кемнәрдер, ә аларны шәһәр халкы бик яхшы белә, яла ягарга маташты. Гәрчә, язмага Ямаш Игәнәй тамгасы куелса да, ул кеше андый эшкә барырдай түгел. Мин аларга газетаның икенче санында ук җавап бирә алыр идем. Дәшмәдем. Дәшмәүдә иде минем бар көч.

– Кулыма каләм алырга мәҗбүр иткән нәрсә гел башкада. Агулы ук бер миңа гына түгел, Президентыбызга да төбәлгән иде. Ул шәхесне якладым мин. Онытма: пәһлеван батырлар да яклауга лаек. Халык яклавына.

*– Язучылар оешмалары белән сәясәт болай бәйләнер дип һич уйламаган идем.*

– Татарстан җөмһүриятендәге тотрыклы хәл Президентыбыз алып барган сәясәт җимеше. Әдәбиятта, сәнгатьтә тормышыбыз бары тик ил тыныч булганда гына ялкынанып дөрли, үсә ала. - Киләчәктә безнең эшчәнлеккә уңыш теләгәндә, Татарстан җиренә иминлек тә сорыйк Ходайдан.

*10 февраль 1995 ел*